**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 5 августы** **64-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча бердәм комиссия турында"» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 1 июлендәге 68-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру буенча бердәм комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында Лаеш муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын булдыру буенча Бердәм комиссия турында» 2023 елның 1 июлендәге 68-РС номерлы карары белән расланган(23.10. 2023 елның 23 октябрендәге 114-РС номерлы карар үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын булдыру буенча Бердәм комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) Комиссия составыннан М.В.Карпованы, Э.Т.Якуповны чыгарырга;

2) комиссия составына кертергә:

Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе Әмирова Айгөл Тәлгать кызын (килешү буенча);

Лаеш муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе Наталья Валентиновнаны;

«Лаеш техник-икътисадый техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) Кузнецова Мария Григорьевнаны;

3) комиссия әгъзасы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федорина Екатерина Петровна - Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Т. Гарифуллинга йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**